12+
DARELFONUN
УНИВЕРСИТЕТ
Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы 11 ноябрь, 2016 ел № 7 (152)



Фото герой архивыннан

# Лаеклы чара! Лаеклы җиңү!

Мәскәүдә «Рус теле игидасы астында уза торган Россия Федерациясе республикалары дәүләт телләре буенча мәктәп укучылары һәм студентларының Россиякүләм олимпиада»сы узды. КФУ данын яклаган Гөлназ Талиповага олимпиада зур тәҗрибә һәм лаеклы җиңү алып килде.

## РИШВӘТЧЕЛЕККӘ КАРШЫ КӨРӘШ

9 нчы ноябрь көнне КФУ ректоры **Илшат Гафуров** ришвәтчелеккә каршы көрәшкә багышланган фәнни конференция эшчәнлегендә катнашты. Конференциянең ачылыш тантанасында Татарстан Президенты **Рөстәм Миңнеханов** КФУның ришвәтчелеккә каршы көрәштә тоткан урынын һәм ирешкән уңышларын ассызыклап узды.

## ЗУР ЧАРА

11-13 нче ноябрь көннәрендә КФУда **Россия политологлары җәмгыятенең II корылтае** узачак. Ике көн дәвамында университетта Россия, Италия, Канада, АКШ, Австрия, Франция, Сербия, Казахстан, Армения, Эстония, Аргентина, Бразилия, Иран, Таиланд, Гватемала галимнәре һәм тагын берничә дистә илдән килгән иң данлыклы политологлар Россия сәясәте һәм аның дөньякүләм мәйдандагы урыны турында сөйләшәчәкләр.

## ОЧРАШУ

Бүген 16.00 сәгатьтә төп бинаның I физик аудиториясендә КФУны тәмамлап, югары дәрәҗәләргә ирешкән студентлар «MOST» проектын эшләтеп җибәрү кысаларында чыгыш ясаячак. Әлеге чара Казан университеты укучыларының буыннар чылбырын ныгытуга һәм тәҗрибә алмашуга юнәлдерелгән. Чараның спикерлары арасында ТР Яшьләр эшләре һәм спорт министры **В.Леонов**, КФУның яшь галиме **Т.Маджидов**, ТАССның Казандагы үзхәбәрчесе **Е.Алеев** та булачак.

# ТАТАР ФӘНЕНЕҢ ҮТКӘНЕ, БҮГЕНГЕСЕ, КИЛӘЧӘГЕ

**Айгөл АБДРАХМАНОВА, Эльвира ЗИННӘТУЛЛИНА**



**КАЗАН (ИДЕЛ БУЕ) ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫ – ТӨРКИ-ТАТАР ТЕЛЛӘРЕ ҺӘМ ТАТАР ФӘНЕН ҮСТЕРӘ ТОРГАН ҮЗӘКЛӘРНЕҢ ИҢ ЗУРЫСЫ. БИРЕДӘ ҺӘРДАИМ ФӘННИ-ГАМӘЛИ КОНФЕРЕНЦИЯЛӘР, ТӨРЛЕ СЕМИНАРЛАР УЗА. 1-4 нче НОЯБРЬ КӨННӘРЕНДӘ КФУНЫҢ Л.ТОЛСТОЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ФИЛОЛОГИЯ ҺӘМ МӘДӘНИЯТАРА БАГЛАНЫШЛАР ИНСТИТУТЫНДА «ЕВРАЗИЯ ГУМАНИТАР ФӘНЕ КОНТЕКСТЫНДА ТАТАР ТЕЛЕ БЕЛЕМЕ» ДИП АТАЛГАН ХАЛЫКАРА ФӘННИ-ГАМӘЛИ КОНФЕРЕНЦИЯ БУЛЫП УЗДЫ.**

Конференцияне Г.Тукай исемендәге Татаристика һәм тюркология югары мәктәбенең Татар теле белеме кафедрасы уздырды. Әлеге чара татар теле белемен өйрәнүгә зур хезмәт куйган галимнәрнең эшчәнлегенә багышланган иде. Конференция кысаларында Гыймад Нугайбәк, Вәли Хангилдин, Галимҗан Шәрәф, Рокыя Шакирова, Әдһәм Тенишев, Вахит Хаков, Диләрә Тумашева, Лия Шакирова, Фирдәвес Гарипова, Абдулла Әсәдуллин, Фәһимә Хисамова, Фәнүзә Нуриеваларның хезмәтләрен барлап, аларга бәя биреп үтелде.

Конференциянең әһәмиятен КФУ студентлары һәм галимнәре генә түгел, бөек галимнәргә хөрмәт йөзеннән чит илләрдән килүчеләр дә бәяләде.

Филология фәннәре докторы, Президент каршындагы Дәүләт идарәсе академиясенең фәнни сәркатибе **Прманова Нажия Акимбек кызы**:

– КФУда уздырылган әлеге конференция – телне өйрәнүдә зур хезмәт куйган шәхесләрне онытмас өчен бик яхшы чара. Яшьләрне шулкадәр киң мирас белән таныштыру бик кирәкле эш. Яңа буын галимнәр остазларының эшләрен дәвам итсеннәр иде.

Филология фәннәре докторы, Л.Н.Гумилев исемендәге Евразия милли университеты (Казахстан) профессоры **Кульдеева Гөлнара Ильяс кызы**:

– Казан университетына, КФУ галимнәренә чиксез хөрмәт һәм соклану гына белдерә алам. 1991 нче елда Казан университеты аспирантурасына белем алырга килдем. Университетта узган елларым тормышымны үзгәртте. Казан лингвистика һәм тюркология мәктәбе безгә төпле белем бирде һәм фәнгә көчле мәхәббәт тәрбияләде. Конференция кысаларында хөрмәтле остазларымны һәм аларның якыннарын күрә алу – минем өчен бәхет. Казан университетында тыңлаган лекцияләрне һәм дәресләрне бүген дә сагынып искә алам. Олпат галимнәрдә һәм шушы искиткеч уку йортында белем алучы КФУ студентлары – бик бәхетле кешеләр.

Конференциягә килгән кунаклар арасында якын күршеләребез дә бар иде. Филология фәннәре докторы, Удмурт дәүләт университеты профессоры **Кельмаков Валей Кельмак улы** КФУ һәм университетта уздырылган әлеге чара турында үз фикерләрен җиткерде:

– Әлеге конференция олпат галимнәрне искә алу гына түгел, яшь галимнәр һәм аспирантлар өчен дә бик кирәкле дип саныйм. Без бүген инде күбесе вафат булган галимнәрне күреп, аларда белем алып кала алдык. Аларның фән дөньясына керткән өлешләре, ачышлары белән бергә, тел үсешен күзәтеп бардык. Яшь галимнәр, бигрәк тә аспирантлар боларны тарих буларак кына белә. Галимнәрне, Казан университеты диварларында ясалган ачышларны искә алу, тарихны яңарту яшьләрне фән белән шөгыльләнергә илһамландыра дип саныйм.

Конференция кысаларында Казан университеты Төркия, Казахстан, Таҗикстан, Финляндия, Кытай, Кырым, Удмуртия, Чувашия, Мәскәү һәм Санкт-Петербург галимнәрен кунак итте.

«Әлеге конференция быел беренче тапкыр уздырылды. Киләчәктә әлеге чараның традиция булып китүенә ышанабыз», – дип уртаклашты Татар теле белеме кафедрасы мөдире, профессор **Галиуллина Гөлшат Рәис кызы**.



Илсөяр Нуретдинова фотолары

3 КӨН, 20 РЕСПУБЛИКА, 137 ФИНАЛИСТ, 6000нән АРТЫК КАТНАШУЧЫ – БОЛАР БАРЫСЫ ДА 1 ОЛИМПИАДА КЫСАЛАРЫНДА. СҮЗ «РУС ТЕЛЕ ИГИДАСЫ АСТЫНДА УЗА ТОРГАН РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ РЕСПУБЛИКАЛАРЫ ДӘҮЛӘТ ТЕЛЛӘРЕ БУЕНЧА МӘКТӘП УКУЧЫЛАРЫ ҺӘМ СТУДЕНТЛАРЫ РОССИЯКҮЛӘМ ОЛИМПИАДА»СЫ ТУРЫНДА. БУ ХАКТА БЕЗ ОЛИМПИАДАНЫ ОЕШТЫРУЧЫЛАРНЫҢ БЕРСЕ – Л.ТОЛСТОЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ФИЛОЛОГИЯ ҺӘМ МӘДӘНИЯТАРА БАГЛАНЫШЛАР ИНСТИТУТЫ ДИРЕКТОРЫ, ФИЛОЛОГИЯ ФӘННӘРЕ ДОКТОРЫ, ПРОФЕССОР **ҖАМАЛЕТДИНОВ РӘДИФ РИФКАТЬ УЛЫ** ҺӘМ ОЛИМПИАДА ПРИЗЕРЫ, КФУ СТУДЕНТЫ **ГӨЛНАЗ ТАЛИПОВА** БЕЛӘН СӨЙЛӘШТЕК.

# КӨТЕЛГӘН ЧАРА! ЛАЕКЛЫ ҖИҢҮ!

Материалны **Айгөл АБДРАХМАНОВА** әзерләде



**РӘДИФ ҖАМАЛЕТДИНОВ:**

Узган уку елында Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы шундый олимпиада уздыруга конкурс игълан итте. Бәйге нәтиҗәләре буенча, КФУ грант отты, һәм без июнь аеннан «Рус теле игидасы астында уза торган Россия Федерациясе республикалары дәүләт телләре буенча мәктәп укучылары һәм студентлары Россиякүләм олимпиада»сын оештыру эшләрен башлап җибәрдек. Без барлыгы 7 вебинар уздырдык. Олимпиаданы оештыручылар белән турыдан-туры онлайн форматта эшләдек, региональ турны ничек уздырырга, биремнәрне ничек формалаштырырга, кемнәр катнаша ала кебек сораулар каралды, балаларны әзерләүче укытучылар белән вебинарлар уздырдык.

Чарада 1000нән артык катнашучы булырга тиеш иде. Нәтиҗәдә исә бәйгегә барлыгы 20 республикадан 6000нән артык кеше гариза тутырды һәм олимпиаданың беренче турында катнашты. Шартлар буенча олимпиада ике турдан торды. Беренчесе төбәкләрнең үзләрендә оештырылса, икенчесе Мәскәүдә Федерация советы бинасында узды. Йомгаклау турын уздыру өчен, үзебезгә партнер буларак, А.С.Пушкин исемендәге Дәүләт рус теле институтын чакырдык. Шулай итеп, төп оештыручылар РФ Мәгариф министрлыгы, Казан (Идел буе) федераль университеты һәм А.С.Пушкин исемендәге Дәүләт рус теле институты булды.

Олимпиадада тупланган баллар нигезендә җиңүчеләр һәм призерлар билгеләнде. Җиңүчеләр алтын медальләр һәм дипломнар, призерлар көмеш медальләр һәм шулай ук дипломнар белән бүләкләнде. Призерлар арасында үзебезнең КФУ студенты булу бик куандырды.

* * *

**ГӨЛНАЗ ТАЛИПОВА:**

Олимпиадада катнашуым һәркем өчен көтелмәгән бер вакыйга булды. Бәйгенең беренче туры онлайн башкарылганын белдем дә, кызык өчен кереп, нәрсә икәнлеген карап чыгарга булдым. Дөресен генә әйткәндә, олимпиада сораулары минем өчен җиңел тоелды. Барысы да университетта укытыла торган фәннәр буенча иде. Миңа калса, бу – үзебезнең КФУ укытучылары биргән белемнең бик яхшы булуы күрсәткече.

Икенче тур Мәскәүдә узды һәм өч өлештән торды. Беренче биремдә һәрбер катнашучыдан эссе яздырдылар. Дөресен генә әйткәндә, сәгать ярым вакыт эчендә фикерләрне туплап бетерү һәм яхшы эчтәлекле, хатасыз эссе язу җиңелләрдән булмады. Тик, балларга караганда, бу биремне бик яхшы эшләгәнмен. Икенче һәм өченче биремнәрне үтәгәндә, туган телдә шигырь сөйләдек (аның русчага тәрҗемәсен белү мәҗбүри шарт иде) һәм «Минем кече һәм зур Ватаным» темасына чыгыш-презентация ясадык. Бик борчылсам да, барысы да уңышлы узды. Әлеге олимпиада барлык катнашучылар өчен дә зур тәҗрибә булгандыр дип саныйм. Бәйге азагында һәрберебезгә эшләребезне карап чыгу, апелляциягә бирү мөмкинлеге бирделәр, хаталарыбызны аңлаттылар. Олимпиаданың оештырылу дәрәҗәсе, катнашучыларга булган мөнәсәбәт бик ошады.

Миңа тапшырылган көмеш медаль КФУ һәм институтыбыз укытучыларының эшчәнлеге нәтиҗәсе дип саныйм.



• Гөлназ Талипова I рәт, уңнан беренче

# КФУ КИЛӘЧӘККӘ ЮЛЛАР ЯРА

**Регина ШИҺАБЕТДИНОВА**

«ФӘННЕҢ УҢЫШЫ АКЫЛ КЫЮЛЫГЫ БЕЛӘН ВАКЫТ ЭШЕННӘН ТОРА», - ДИГӘН ВОЛЬТЕР. ВАКЫТ ГАЛИҖӘНӘПЛӘРЕ БЕР ДӘ ТУКТАМЫЙ, Ә КЫЮ АКЫЛЛАР ИСӘ БҮГЕН ҖИТӘРЛЕК. БИГРӘК ТӘ КАЗАН ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫНДА. 10 НОЯБРЬДӘ БИЛГЕЛӘНЕП ҮТӘ ТОРГАН БӨТЕНДӨНЬЯ ТЫНЫЧЛЫК ҺӘМ ҮСЕШКӘ БАГЫШЛАНГАН ФӘН КӨНЕ УКУ ЙОРТЫБЫЗДА КҮПЛӘР ӨЧЕН ӘҺӘМИЯТЛЕ.

КФУ фән белән шөгыльләнүчеләр өчен бөтен мөмкинлекләрне дә булдыра. Россиядә иң өлкән уку йортларының берсе буларак, фән белән аерылгысыз бәйләнештә эшли. Дөньякүләм танылган фәнни мәктәпләр дә Казан университетыннан башлангыч алган. Н.И. Лобачевский, И.М.Симонов, Н.Н. Зинин, А.М. Бутлеров, В.М. Бехтерев, И.А.Бодуэн де Куртенэ, В.П. Васильев, Н.Г. Чеботарев һәм башка бик күп билгеле шәхесләрнең исеме Казан университеты белән бәйле.

Студентларны фәнгә булган гади кызыксынудан олы фән юлына илтүче мөгаллимнәр КФУда шактый күп икән: фәнни-эзләнү эшен башкаручылары – 3 меңнән артык, шуларның 400дән артыгы – фән докторлары, 2 меңгә якыны – фән кандидатлары. Яшь белгечләр, галимнәр исә фәнни-педагогик хезмәткәрләрнең 46,5%ын тәшкил итә.

Бүгенге КФУ – ул яхшы үсеш алган инфраструктуралы, әйдәп бара торган фәнни үзәк. Университет үсешенең өстенлекле фәнни юнәлешләре:

- биомедицина һәм фармацевтика;
- перспективалы материаллар;
- нефть табу, нефть эшкәртү, нефтехимия;
- инфокоммуникация һәм галәм технологияләре.

Шул юнәлешләр буенча фәнни-эзләнү эшчәнлеге 2014 елда ачылган дөньякүләм югары дәрәҗәдәге OpenLab лабораторияләрендә башкарыла.

Эзләнүләрнең чыганагы кайда соң? Уку барышында КФУ студентлары 1 курстан башлап фәнни эш белән шөгыльләнә. КФУның фәнни-йомгаклау конференциясе, иң яхшы фәнни эш бәйгесе, студентлар өчен «Грани науки» электрон фәнни журналы һәм бихисап грант бәйгеләре галим булырдай сәләтле яшьләрне табарга ярдәм итә. Ел саен уку йорты нигезендә 200ләп конференция үтә, яртысыннан күбрәге – халыкара киңлектә.

Фәнни-тикшеренү эшләренең төп нәтиҗәләре һәр ел саен 8 меңнән артык мәкалә, доклад тезислары, монография, уку ярдәмлекләре форматында дөнья күрә. Гадәттә, 500дән артык фәнни эшне чит илдә бастыралар.

КФУда яшь эзләнүчеләргә ярдәм итү буенча төрле программалар каралган. Студентлар һәм магистрантлар өчен ел саен төрле дәрәҗәдәге стипендияләр тәкъдим ителә. Араларында иң абруйлысы – РФ Президенты һәм Хөкүмәте стипендияләре.

Башкарылган фәнни хезмәтләрнең гамәлгә ашырылуы да бик мөһим фактор. Университетның партнерлары арасында «ТНГ-групп» ҖЧҖ, «Нижнекамскнефтехим» ААҖ, «Алексеевская керамика» ҖЧҖ һ.б. бар. Чит ил югары уку йортлары белән алмашып уку, практика узу программалары нигезендә КФУ берничә дистә университет белән хезмәттәшлек итә.

КФУ фән гранитын кимереп кенә калмый, киләчәк буын өчен яңаларын таба һәм яшь галимнәргә яңа юллар яра.



Фото sfy-conf.com сайтыннан алынды



• Алексей Андреев



• Лия Вәлиева



• Руслан Гайфетдинов



• Диләрә Хөснетдинова

Әле күптән түгел Казанда Россия буенча елның иң әһәмиятле фәнни вакыйгаларының берсе «Наука будущего» («Киләчәк фәне») II Халыкара фәнни конференция һәм II «Наука будущего – наука молодых» («Киләчәк фәне – яшьләр фәне») форумы узган иде. Араларында, әлбәттә, безнекеләр дә бар. Кемнәр соң алар? Нинди юнәлештә җиңү яулаганнар?

**ЛИЯ ВӘЛИЕВА – 1 урын. «Агро, био, сәүдә технологияләре» юнәлеше; Фундаменталь медицина һәм биология институты аспиранты:**

– Фәнни хезмәтем үсемлекләр туклануында фосфор җитмәү мәсьәләсен чишүгә бәйле. Фосфор – үсемлек күзәнәкләренең дөрес эшләве өчен бик мөһим элемент. Ләкин үсемлекләр һәм хайваннар өчен кирәкле органик булмаган фосфат елдан-ел кими. Шунлыктан фәнни эшебездә без аны синтезлау, җитештерү якларын карадык. Махсус генны Arabidopsis thaliana үсемлегенә кушып, фосфор җитештерә алырдай мохит булдырдык.

Технологияне авыл хуҗалыгында киң кулланырга мөмкин. Беренчедән, фосфор өстәмәләрен һәм химик ашламаларны экономияләү мөмкинлеге туа, икенчедән, мал-туар өчен әзерләнгән азык файдалырак була.

**РУСЛАН ГАЙФЕТДИНОВ – 3 урын. «Җир турында фәннәр, экология һәм табигый ресурслардан рациональ файдалану» юнәлеше; Геология һәм нефть-газ технологияләре институты аспиранты:**

– Нефтьнең җитешкәнлеген, суландыруның нәтиҗәлелеген бәяләү һәм нефть запасларын тулыландыра алырдай урыннарны ачыклау максатыннан, Первомайск-Бондюжск туфрак өеменең төзелешен өйрәнергә булдык. Хезмәтнең төп темасы да нәкъ шул. Эшнең зур өлеше минем «Татнефть» компаниясендә 4 ай дәвамында узган практика чорында башкарылды. Тикшеренү үзе 2014 елның июненнән 2015 елның ноябренә кадәр барды.

Безнең нәтиҗәләргә нигезләнеп, нефть урнашкан җирләр күрсәтелгән яңа карталар төзелде һәм скважиналарның эшчәнлеге уңай якка үзгәрде. Шул сәбәпле нефть табу тәүлегенә 7 тоннага артты.

**АЛЕКСЕЙ АНДРЕЕВ – 1 урын. «Физика һәм астрономия» юнәлеше; Физика институты магистры:**

– Физиканы мин мәктәптән үк үз иттем, бу фән өлкәсендә эшчәнлекне 1 курста ук башладым. Бүген исә, физик либрация параметрларын дөресләү максатыннан, сферик функцияләр буенча таркалуның гармоник анализы нигезендә фигурага карата күк җисемнәре массаларының үзәк урынын билгеләргә тырышам.

Хезмәт Җир-Ай системасына нигезләнгән, чөнки галәмнең барлык заманча миссияләрен исәпләү аңа таянып башкарыла. Әлеге тикшеренү вакыт-координата төгәллеген арттыра. Өстәвенә аны башка күк җисемнәрен, әйтик, Марс һәм аның иярченнәре Фобос белән Деймосны өйрәнүдә кулланырга мөмкин.

**ДИЛӘРӘ ХӨСНЕТДИНОВА – конференция кысаларында узган «Умник» бәйгесе лауреаты. Фундаменталь медицина һәм биология институты аспиранты:**

– КФУның 5 курсында укыганда, эчәклекнең микробиом составын өйрәнә башладым. Ул вакытта Helicobacter pylori бактериясенә бәйле шактый киң күләмле тикшеренүләр бара иде. Баксаң, һәркемнең эчәклек микрофлорасы үзенчәлекле, бер-берсеннән шактый аерыла икән. Димәк, дәвалану вакытында һәр авыру антибиотикларга төрлечә реакция бирә һәм һәркемгә аерым билгеләнгән доза булдырырга кирәк.

Үзебезнең тикшеренүләрдә без бу авыруны башлангычында ук билгеләргә омтылдык. Организмдагы патологияне башлангыч стадиясендә ачыклап, дәвалау чараларын күпкә иртәрәк күрергә була.

***P.S.:*** Күргәнебезчә, КФУда фән белән шөгыльләнергә мөмкинлекләр зур. Кайбер тикшеренүләрне хәзергә сүз белән аңлатырга да авыр. Һәркем нинди өлкәдә көчле, шул юнәлештә фәнни эшчәнлек алып бара ала.

«Фәнни планда «Киләчәк фәне» – уникаль конференция. Мин программасында барлык фәннәрдән дә темалар тәкъдим ителгән башка конференцияне белмим», – диде үзенең чыгышында конференциянең программа комитеты рәисенең берсе, профессор **Александр Кабанов**.

Яшь галимнәргә бу чара вакытында күрсәтелгән ярдәм һәм аларны илебез лабораторияләрендәге эшкә тарту фәнгә яңа лидерлар бирә. Форумны һәм конференцияне дәвамлы итү Россиядә фән үсеше өчен мөһим фактор булып тора.

«Киләчәк фәне – яшьләр фәне» форумы

| 4 | 42 | 1300 | 39 |
|---|---|---|---|
| көн | илдән | катнашучы | җиңүче |

# БЕЗ БЕЛМӘГӘН ЯҢА ТАТАР БИСТӘСЕ

Раил САДРЕТДИНОВ

БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР ЯШЬЛӘРЕ ФОРУМЫ ВӘКИЛЛӘРЕ «БИСТӘ 2.0» ПРОЕКТЫН ЭШЛӘТЕП ҖИБӘРДЕ. МАКСАТ – ЯҢА ТАТАР БИСТӘСЕ ПРОБЛЕМАСЫНА ҖӘМӘГАТЬЧЕЛЕКНЕҢ ИГЪТИБАРЫН ЮНӘЛТҮ.

*«Илебездә 20дән артык татар бистәсе бар. Күп шәһәрләрдә алар начар хәлдә. Томск, Оренбург, Омск, Мәскәү, Белоруссия, Казахстанның Семипалатинск шәһәрләрендә дә татар бистәләре булган. Тик аларның тарихлары өйрәнелмәгән. Бу – бик кыйммәтле тарих. Чөнки кайчандыр анда татар халкы яшәгән, шәһәр үсешенә үз өлешен керткән. Бу мирасны саклыйсы, өйрәнәсе, киләчәк буыннарга җиткерәсе бар әле. Бистәләрнең тарихын барлау, актуальләштерү, халыкка җиткерү Бөтендөнья татар яшьләре форумының күптәнге хыялы иде»*, – дип сүзен башлады рәис урынбасары, КФУны тәмамлаган яшь тарихчы **Айрат Фәйзрахманов**.

... Яңа татар бистәсе тарихына күз салсак, ул XVIII гасырның икенче яртысында Казанда көчләп чукындыру сәясәте шаукымы нәтиҗәсендә барлыкка килгән һәм иске бистәдән зуррак мәйдан биләп торган. Әлеге бистәнең чикләре Мехчы, Гафури, Кызыл Татарстан урамнары белән билгеләнә. Бистәнең күп өлешен сәнәгать зонасы алып торганга, биредә эшче халык яшәгән. Авылдан бәхет эзләп килгән халык та Яңа татар бистәсен үз иткән. Биредә татар байлары үз капиталларын булдырганнар. Дөрес, бүген татар тарихы белән бәйле биналар аз сакланып калган. Айрат шуларның берничәсенә аерым тукталды: Ак мәчет 1801 елда төзелә, быел аңа – 215 ел. Кызганыч, бүген ул җимерек хәлдә. Мәчет озак вакытлар мех эшкәртү фабрикасы территориясендә була, совет вакытында мәктәп ролен дә үти. Икенче объект – иске таш мәчет. Манарасы совет чорында да киселми. Биредә Фатих Әмирханның әтисе, бабасы имам булып торганнар. Әмирхания мәдрәсәсен тотканнар. Яңа татар бистәсенең тагын бер истәлекле ядкәре – Исламны кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә урнашкан Ал мәчет тә XIX гасыр башында төзелгән.

1928 елда бистәдә, Мех фабрикасы төзелү сәбәпле, тормыш сүрелә төшә. Яңа татар бистәсенең тарихын күрсәтерлек биналарның 90%ы инде юк ителгән. Татар рухын саклаган 3 мәчет, зират бар. Бүгенге көндә, территориянең яртысын биләп торган сәнәгать зонасы яңарыш кичерә. *«Тиздән, Президент кушуы буенча, Малайзия архитекторлары мехкомбинат территориясен яңарту проектларын тәкъдим итәчәкләр. Нәкъ шуңа күрә без Яңа татар бистәсе буенча әлеге тарихны барлый башладык. Аны әлеге проектны әзерләүчеләргә дә җиткерергә уйлыйбыз. Без эшләгән «Бистә 2.0» проекты турында шәһәр архитектура идарәсеннән дә мәгълүмат сорадылар»*, – диде Айрат.

Яңа татар бистәсенә беренче экскурсия сентябрьнең яңгырлы бер көнендә оештырылды. Көтелгән 15-20 кеше урынына 100ләп кеше җыелды. 2 сәгатьлек экскурсия дәвамында 4-5 км юл үтелде. Яңа татар бистәсенә кергән Плҗтән җирлегендә, Әҗем мәчете янында урнашкан, хәзер биналар астында калган зиратта булдылар. Шул вакыт эчендә кешеләрнең таралмавы, аларның арта гына баруы команданы тагын да зуррак эшләргә рухландыра.

Узган атнада гына форумчылар Казандагы тагын бер бистәгә – Бишбалтага экскурсия оештырды. Тарихтан мәгълүм ки, Казан ханлыгы чорында ук биредә кораблар төзелә. Иң зур объект – Казан ханлыгы чорыннан калган борынгы зират. Бу территория Адмиралтейство бистәсен торгызу проектына мемориаль зона буларак керер, дип ышана форумчылар.

> *Яңа татар бистәсенең тарихын күрсәтерлек биналарның 90%ы инде юк ителгән*

Киләчәктә 3 бистә – Иске татар бистәсе, Плҗтән һәм Яңа татар бистәсе аша үтә торган туристик маршрут барлыкка килергә дә мөмкин. Шулай ук төзекләндерелгән парк-скверлар, су буйлары, велосипед юллары бүгенгә татлы хыял булып кала бирә. *«Биналарда утырып, тарихны саклап булмый. Ачык һавада татар мәдәниятенә караган чаралар, фестивальләр уздырырга кирәк. Без әлегә тәкъдимнәрне язабыз, барлыйбыз һәм чынга ашырырбыз дип уйлыйбыз»*, – диде Айрат Фәйзрахманов әңгәмәбез ахырында.



Лилия Туктарова фотосы

КФУның ЖУРНАЛИСТИКА һӘМ МЕДИАКОММУНИКАЦИЯ ЮГАРЫ МӘКТӘБЕ НИГЕЗЕНДӘ һӘР АТНА САЕН КЫЗЫКЛЫ ШӘХЕСЛӘР БЕЛӘН ОЧРАШУЛАР һӘМ ТӨРЛЕ ТЕМАЛАРГА ОСТАХАНӘЛӘР УЗА.
8 НОЯБРЬ КӨННЕ СТУДЕНТЛАР «БИЗНЕС ONLINE»ГА НИГЕЗ САЛУЧЫ, «ТАТСПИРТПРОМ» АҖнең МӘГЪЛҮМАТИ СӘЯСӘТ БУЕНЧА ДИРЕКТОР УРЫНБАСАРЫ РИНАТ БИЛАЛОВ БЕЛӘН ОЧРАШТЫ.


Дилярә Кашапова фотосы

# АЧЫКТАН-АЧЫК СӨЙЛӘШУ

**Алинә СЫСОЕВА,** Журналистика һәм медиакоммуникация югары мәктәбе

Очрашу барышында **Ринат Билалов** уңышлы мультимедия гаммәви мәгълүмат чарасын булдыру серләрен ачты. Үз проектыңны башлаганда, исәпкә алырга кирәк булган төп аспектлар, команда туплау үзенчәлекләре турында сөйләде һәм хәзерге журналистикага булган мөнәсәбәтен белдерде.

Моннан тыш Ринат Билалов үзе башлап җибәргән «БИЗНЕС Online» проекты, интернет челтәрендә эшләүнең уңай һәм тискәре яклары турында сөйләде. «Журналист универсаль, һәр яктан белемле шәхес булырга тиеш», – диде ул. Билалов фикеренчә, журналистиканың киләчәге интернет һәм блоггинг белән турыдан-туры бәйле икән. Шуңа күрә журналистика һөнәрен сайлаган һәркем социаль челтәрләрдә актив эшчәнлек алып барырга, укучылар белән һәрвакыт аралашып торырга тиеш дип тә белдерде.

Очрашуга килгән студентларга исә уку һәм практика арасында алтын урталык таба алуларын һәм блоггинг өлкәсендә үзләрен сынап карауларын теләде.

• **Сораштыру**

17 НОЯБРЬ – КАЗАН ИМПЕРАТОР УНИВЕРСИТЕТЫНЫҢ ТУГАН КӨНЕ. МОННАН 212 ЕЛ ЭЛЕК, ЯГЪНИ 1804 ЕЛДА, ПАТША АЛЕКСАНДР I КАЗАН ИМПЕРАТОР УНИВЕРСИТЕТЫНА НИГЕЗ САЛУ ТУРЫНДАГЫ РАСЛАУ ГРАМОТАСЫН һӘМ УСТАВЫН ИМЗАЛЫЙ. ИДЕЛ БУЕНДА КӨЧЛЕ ФӘННИ ҮЗӘК ДӨНЬЯГА АВАЗ САЛА. Ә СТУДЕНТЛАРЫБЫЗ БУ ТАРИХИ ДАТАНЫ БЕЛӘЛӘРМЕ ИКӘН?




# МОНЫ БЕЛУ КИРӘК!

• АЛСУ ГАЗТДИНОВА, **Журналистика һәм медиакоммуникация югары мәктәбе магистры:**

Хатирәләр бик бай: 12 ел элек, университетның 200 еллык юбилеен билгеләп үткәндә, мин дә 1 нче курс студенты буларак катнашкан идем. УНИКСта университетны төрле елларда тәмамлаган, төрле илләрдән килгән элеккеге студентлар җыелган иде, «Гаудеамус»ны җырладылар. Быел исә 17 ноябрь – уку көне. Бәлки, берәр чарага бару мөмкинлеге булыр, әлегә белмим.

• ЛӘЙЛӘ ХӘБИБУЛЛИНА, **Г.Тукай исемендәге Татаристика һәм тюркология югары мәктәбе магистры:**

17 ноябрь кичендә «Калеб: Яңа буын җыены» проекты кысаларында яшь шагыйрьләрне тәкъдим итү кичәсе – «Яңа дулкын» булачак. Мәртәбәле жюри алдында үз иҗатыңны күрсәтү, аны тамашачыларга җиткерү җиңел эш түгел.

• АЙЗИРӘК САДЫЙКОВ, **Фундаменталь медицина һәм биология институты:**

Укыйм инде, Алла боерса. 13:35-18:30 арасындагы парлар бик әһәмиятле: бу фәннәрдән без имтихан бирәчәкбез.

• АЛСУ ЗИННУРОВА, **Журналистика һәм медиакоммуникация югары мәктәбе магистры:**

Нинди бәйрәм соң әле ул көнне? (*уйланып*). Төркемдәшем Илүзәнең туган көне! Форсаттан файдаланып, туган көнең белән, Илүзә.

Сораштырудан күренгәнчә, ни кызганыч, студентларыбызның күбесе 17 ноябрь – Казан император университетының туган көне икәнен белми. Юкса, үз тарихын белмәгәннең киләчәге юк дип күпме сөйлибез…

**Туган көнең белән, мәңге яшь, заманча, гыйлемле Казан университеты!**

# «БИКАФЕСТ – 2016»: НИ КӨТӘРГӘ?

**Марсилә ФӘХРЕТДИНОВА,** Журналистика һәм медиакоммуникация югары мәктәбе

19-20 нче НОЯБРЬ КӨННӘРЕНДӘ РӨСТӘМ БИКМУЛЛИН ИСЕМЕНДӘГЕ XV РЕСПУБЛИКАКҮЛӘМ «БИКАФЕСТ» ЯШЬЛӘР ҖЫР-ШИГЪРИЯТ ФЕСТИВАЛЕ ҮТКӘРЕЛӘЧӘК.

Фестивальдә 12-25 яшькәчә егет-кызлар катнаша ала. Әлеге чараны Казан (Идел буе) федераль университеты, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы, «Сәләт» фонды бергәләп үткәрә. Һәр елны оештыручылар нинди дә булса яңалык кертәләр, һәр фестивальне истә кала торган итәргә тырышалар. Быел «БикаФест»ның зарыгып көтеп алынган юбилее. Катнашучылар өчен һәрвакыт төп сюрприз – жюри әгъзалары. Гариза тутыру этабы беткәнче, оештыручылар аларны сер итеп саклый. Узган 3 елда җыр номинациясендә жюри рәисе **Римма Ибраһимова** һәм **Айдар Файзрахманов** булды. Элек әлеге фестивальдә җиңү яулап, хәзер жюри кәнәфиендә утыручылар да бар. Яшь җырчы, «Сәләт» ветераны **Илназ Сафиуллин** шундыйлардан. Тагын бер үзенчәлек: катнашучылар чыгыш ясау чиратын көткәндә, алар өчен махсус мастер-класслар, очрашулар каралган.

«Сәләт клубы» президенты **Айгөл Габдрахманова** әйтүенчә, «БикаФест» өч өлештән тора: гаризаларны кабул итү, катнашучыларны сайлап алу һәм зур гала-концерт. Фестиваль җылы гаилә атмосферасында үтә. Биредә катнашучылар бер-берсе белән аралашып, яңа иҗатташ дуслар табалар.

# Эзлим сине яки 21 гасыр «афәт»е

**Раилә ВӘЛИУЛЛИНА,** Журналистика һәм медиакоммуникация югары мәктәбе

**XXI ГАСЫР – ТОРМЫШЫБЫЗ АЛГА КИТКӘН, КЕШЕЛЕКНЕҢ АҢ-БЕЛЕМ ДӘРӘҖӘСЕ ҮСКӘН, ТЕХНОЛОГИЯЛӘР КАМИЛЛӘШӘ БАРГАН ЧОР, ДИБЕЗ. ЯШЬЛӘРНЕҢ ГЕНӘ ТҮГЕЛ, УРТА БУЫН ВӘКИЛЛӘРЕНЕҢ ДӘ ҺӘРБЕРСЕНДӘ ТЕЛЕФОН, СМАРТФОН БИТ ХӘЗЕР, ИСЕҢ КИТӘРЛЕК! ӘЛЕ КАЙЧАН ГЫНА НИНДИДЕР БЕР МОГҖИЗА БУЛЫП ТОЕЛГАН НӘРСӘЛӘР БЕЗНЕҢ ӨЧЕН ГАП-ГАДИ КҮРЕНЕШКӘ ӘЙЛӘНДЕ.**

Әйе, сүз дә юк, рәхәт хәзер тормыш. Һәр йортка ут, су кертелгән, телевизорлар гөрләп эшләп тора, телефон аша гына хәлләрне белешәбез, интернеттан язышып аралашабыз. Әмма, төптән уйлап карасак, аралашу өчен уйлап табылган бу җайланмалар үз вазыйфаларын бөтенләй капма-каршыга үзгәртте түгелме соң? Кешеләрне берберсеннән аера, ерагайта алар. Дөнья мәшәкатьләрен бер якка куеп, күршебезгә хәл белешергә соңгы тапкыр кайчан кердек икән? Бернинди сәбәпсез генә дустуганнар белән җыелышып сөйләшкәнебез бармы? Вакыт юклыкны сылтау итеп, телефоннан яки социаль челтәрдән хәл-әхвәл сорашып язучылар бардыр, әлбәттә. Әмма, кара-каршы утырып, чын күңелдән сөйләшүгә җитәме соң ул?



Автор фотосы

Бу мәсьәлә бигрәк тә яшьләргә кагыла. Мәсәлән, һәр иртә, укырга барырга дип, бүлмәдәш кызларым белән тукталышка чабабыз. Студентлар белән шыгрым тулы автобуска көч-хәл белән килеп керәбез. Кеше күп, тик автобус әллә нинди җансыз кебек тоела. Ник дигәндә, бөтенесе телефонга текәлгәннәр, кайсы социаль челтәрдә яңалыклар тасмасын күзәтә, кайсы, кызып-кызып дөнья хәлләрен сөйләшә. Кайберәүләр виртуаль дөньяга шулкадәр кереп киткәннәр ки, хәтта яннарында басып торган реаль кешеләргә игътибар да итми. Бөтен автобуска чын әңгәмә алып баручы, күп булса, дүрт-биш кеше бардыр. Әле алары да өлкән буын кешеләре. Өлкәннәр әйтмешли, яшьлегең бар, матурлыгың бар, таныш, сөйләш инде шунда тирә-юньдәгеләр белән, араларында нинди генә кызыклы шәхесләр булмас. Әмма яшьләр телефонга текәлеп баруны барыбер дә кулайрак күрәләр.

Танышу димәктән, егет һәм кызлар арасында да упкын тудыра бит әле бу интернет дигәннәре. Кайберәүләрнең шушы «афәт» аркасында хәтта чынбарлыкта сүз катарга кыюлыклары җитми башлады. Шуңа да хәзер социаль челтәрләрдә «Эзлим сине», «Көтелмәгән мәхәббәт» кебек төркемнәр бихисап. Кереп укып карасаң, аптырашта калдыра торган язмалар бар. Мәсәлән, Казан шәһәренең шундый бер төркемендә: «Шул-шул урамда бер кызны күрдем, озын кара чәчле, кызыл куртка кигән, кулында кара сумка иде. Син миңа бик ошадың. Үзеңне танысаң, бу язмага «лайк» куйчы» һәм шуның ише бик күп хәбәрләргә тап булдым. Егет кеше кызның нинди киемнән булуына хәтле белә, еш кына аның янында ук басып тора, ә танышырга дигәндә каушап кала. «Юк, булмый, куркам. Менә кайтырмын да интернеттан эзләп табармын әле», – дип уйлый да төркемгә яза егет. Җайлы бит: каракаршы уңайсызланып басып торасы, сүз таба алмыйча интегәсе юк.

Ләкин яшьлекнең бар матурлыгы, бар кызыгы да шунда бит инде. Олыгайган көндә интернеттан язышуың түгел, ә нәкъ менә шул каушый-каушый сөйләшүләр искә төшәчәк. Чын аралашуны интернеттан язышуга алыштырып, яшьләр иң матур елларын әрәмгә уздыралар, үзләрен гомер буе озатып киләчәк якты хатирәләрдән мәхрүм итәләр.

Техника ничек кенә алга китмәсен, аның ярдәмендә аралашу барыбер җансыз булып кала бирә, ә җансыз әңгәмә ягылмаган мич кебек бит ул – күңелне җылытмый. Интернет, телефонны бер читкә куеп, чынбарлыкта күзгә күз карашып сөйләшергә, шул сөйләшүнең тәмен белергә өйрәнсәк иде.

12+
DARELFONUN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Мөхәррир в.б. - Л.Р.Сабирова
Иҗат коллективы:
Р.Р.Садретдинов,
А.А.Абдрахманова
Корректор - Р.Ә.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – ФГАОУ ВО Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 334 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru
Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2016 елның 08 сентябрендә ПИ № ТУ 16-01506 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00, 10.11.2016. «Фолиант» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Профсоюзная, 17в.